**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423646 Республика Татарстан, Менделеевский район, д.Псеево ул. Центральная, д.4

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423646 Татарстан Республикасы, Менделеевск районы Песәй авылы, Үзәк урам,4 йорт

Тел. (факс): (85549) 3-71-22 e-mail: Psv.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.07.2024 ел № 5

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
«Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
жирдән файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләре проекты буенча
гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 - 33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге уставы, Песәй авыл җирлегенең 2018 елның 28 августындагы 85 номерлы карары (2022 елның 19 декабрендәге 67 номерлы карары үзгәрешләре белән) белән расланган "Татарстан Республикасы Песәй авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә" нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә гавами тыңлаулар уздыру юлы белән фикер алышуда катнашу хокукын үтәү максатларында карар бирәм:

1. 2024 елның 8 августы 16 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Псеев авылы, Мәктәп тыкрыгы, 3 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән сорау буенча түбәндәге составта гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен комиссия төзергә:

Мөхәммәтгалиев Вилдан Илсур улы - Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе;

Ситдыйкова Гөлназ Илдус кызы - Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе, комиссия сәркатибе;

Мөхәммәтгалиев Илшат Гарифиан улы - Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге рәисе урынбасары, комиссия әгъзасы;

Тимербаев Наил Шакирҗан улы - Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге советы депутаты, комиссия әгъзасы.

3. 2024 елның 9 июленнән 8 августына кадәр

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча материаллар экспозициясен Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Песәй авылы, Үзәк ур., 4 йорт адресы буенча Песәй авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында оештырырга

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 423646, Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Песәй авылы., Үзәк ур., 4 йорт адресы буенча ( Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге башлыгы исеменә) кабул ителә (җибәрелә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Песәй авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Халык җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районының
Песәй авыл җирлеге башлыгы _____ В.И.Мөхәммәтгалиев